**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**

**Чубар-Абдулловского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы БАШЛЫГЫ

ул. Советская, д. 81 , село Чубар-Абдуллово
Азнакаевского муниципального района,
423323
Тел. (факс) (85592)38-7-37
Chabd.Azn@tatar.ru

Совет урамы, 81, Чубар-Абдул авылы
Азнакай муниципаль районы, 4233237
Тел. (факс) (85592) 38-7-37
Chab.Azn@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» ноябрь 2021 года № 4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең Чубар-Абдул торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Чубар-Абдул авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2021 елның 2 дераберендә 10 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә Яшьләр урамы 1 йорттан 13 йортка кадәр, , Комсомол урамы 1 йорттан 28 йортка кадәр.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Чубар-Абдул авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2021елның 2 декаберендә 11 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә: Чапаев урамы 1 йорттан 48 йортка кадәр, Совет урамы 86 йорттан 119 йортка кадәр.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Чубар-Абдул авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2021елның 2 декаберендә 12 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә: Совет урамы 1 йорттан 85 йортка кадәр.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елдаЧубар-Абдул авыл җирлеге Чубар-Абдул торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (Яңа ел, Җиңү көне, Сабантуй, Халыкара өлкәннәр көне);
- урам утларын, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, энергия саклаучы лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түлә;
- контейнер мәйданчыклары урнаштыру (киртәләр алу, киртәләр ясау һәм урнаштыру, нигез урнаштыру, контейнерлар сатып алу);
- Совет урамы буенча күперне ремонтлау (материаллар сатып алу, контракт буенча эшләр өчен түләү);
- Чапаев урамы буенча гравий капламы белән юллар салу (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);

« РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Чубар-Абдул авылы, Совет ур., 85 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык: Н. Ә. Фәтхетдинов